СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 12-22 от «28» июля 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 26 мартындагы "Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлегенең генераль планы турында" 8-6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Мамадыш районы прокуратурасының 2023 елның 13 июнендәге 02-01-19-2023 номерлы тәкъдиме, “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма” авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2021 елның 26 мартындагы "Мамадыш муниципаль районы Түбән Ушма авыл җирлегенең генераль планы турында" 8-6 номерлы карарына (алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 18 таблица сындагы 2 абзацында “туфракның уңдырышлылыгын көйләү” сүзләрен “туфракның уңдырышлылыгын күтәрү” сүзләренә алыштырырга;

1.2. нефть чыгару объектларында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча чараның 58 нче бүлегенең абзацында икенче өлешкә ” һәм гидротехник корылманың куркынычсызлык дәрәҗәсен нигезләү (нормаль, түбәнәйтелгән, канәгатьләнерлек түгел, куркыныч) сүзләрен, “гидротехник корылманың куркынычсызлык дәрәҗәсе башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органнары тарафыннан гидротехник корылманың куркынычсызлык декларацияләре расланганда билгеләнә” җөмләсен өстәргә.

1.3. мелиорацияләнә торган авыл хуҗалыгы җирләре бүлегенең 1 абзацында "һәм мелиоратив саклагыч урман утыртмаларын" сүзләрен "һәм агроурман мелиоратив утыртмаларны, агрофитомелиоратив утыртмаларны куллануны" сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарның 1.2 пункты 2024 елның 1 сентябреннән, 1.3. пункты 01.03.2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет-телекоммуникация

000057

челтәрендә Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының җирле үзидарә, аграр сәясәт, җирдән файдалану һәм экология буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе

А.П.Иванов